ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАЧЕЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 200, с.Качелино,
Арский муниципальный район, 422013

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘЧЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк урам, 200 йорт, Кәче авылы,
Арча муниципаль районы, 422013

Тел. (84366)52-3-93, факс (84366)52-3-93. E-mail:Kach.Ars@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от «23» декабрь 2025 ел** **№ 67**

**Пиротехник эшләнмәләрдән файдалану өчен рөхсәт ителгән урыннарны билгеләү турында**

Яңа ел бәйрәм чаралары чорында гражданнарның гомере һәм сәламәтлеге иминлеген, физик һәм юридик затларның мөлкәтен, дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне тәэмин итү максатларында, “Янгын куркынычсызлыгы турында” 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы һәм “Янгын куркынычсызлыгы турында”1993 елның 18 маендагы 1866-XXII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында” 22.12.2025 ел 1121 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы тәкъдимнәрен исәпкә алып, Кәче авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. “Биеклеге 50 метрдан артык булган салютлар һәм фейерверклар үткәргәндә, шулай ук җир яисә су өслегенә һава юллары полосаларын проекцияләү чикләрендә, салютлар һәм фейерверклар биеклегенә бәйсез рәвештә, һава киңлегеннән файдалану Россия Федерациясе Һава хәрәкәтен оештыруның бердәм системасының оператив органы рөхсәте белән гамәлгә ашырыла (алга таба - Вәкаләтле орган).

Фейерверк уздыру өчен вәкаләтле органнан рөхсәт алырга кирәк. Язма рөхсәттән башка муниципаль берәмлек территориясендә фейерверк уздыру тыела.”

2. Пиротехник эшләнмәләрдән файдалану өчен рөхсәт ителгән урыннар дип түбәндәгеләрне билгеләргә:

- Кәче авылы көнькка таба Чулпан авылы ягына таба, торак пункттан 300 метр ераклыкта;
- Чулпан авылы төньяк-көнчыгыш юнәлештә торак пункттан 300 метр ераклыкта;
- Якты-Көн авылы төньяк- көнчыгыш юнәлештә торак пункттан 300 метр ераклыкта.

3. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм Кәче авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Кәче авылы, Үзәк урам, 200 йорты; Чулпан авылы, Гагарин урамы, 7а йорт; Якты-Көн авылы, Якты урам 30а йорт.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Кәче авыл җирлеге
башлыгы Р.Р.Гәрәев